**Республика Татарстан САКЛОВ-БАШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

ИНН/КПП 1636005510/164701001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2021 г. № 16

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә, вәкаләтләрнең бер өлешен, карар буенча җирле әһәмияттә кабул иту турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешенә һәм 14 статьясындагы 1 өлешнең 20 пунктына кергән үзгәрешләр, ТР Сарман муниципаль районы Советының «шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында» 19.04.20021 номерлы карары, Саклаубаш авыл җирлеге советының «Саклаубаш авыл җирлеге муниөипалҗ берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында” карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча» Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:
- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау һәм үзгәрешләр кертү.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар бер елга билгеләнә һәм ул басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль

районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

Саклаубаш авыл җирлеге
Советы Рәисе

Л. М. Габидуллина